СОВЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.14, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

Совет мәйданы, 14 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-11-33, факс (84366)3-01-33, 3-14-33. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**Арча район Советы**
**КАРАРЫ**

**« 13 » ноябрь 2019 ел** **№ 285**

**"Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының муниципаль мөлкәт Исемлегенә кертелгән, өченче затлар хокукыннан азат булган (хуҗалык алып бару хокукыннан, оператив идарә хокукыннан, шулай ук кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш), кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына биләүгә һәм (яки) файдалануга бирү өчен билгеләнгән муниципаль мөлкәтен, шул исәптән җир кишәрлекләрен (шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, яшелчәчелек, бакчачылык, шәхси торак төзелеше өчен билгеләнгән җир кишәрлекләреннән тыш) арендага бирү Тәртибен һәм Исемлеккә кертелгән муниципаль мөлкәтне формалаштыру, алып бару һәм мәҗбүри бастырып чыгару Тәртибен раслау турында"**

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы территориясендә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын төзүче оешмаларга мөлкәти ярдәм күрсәтү максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясына, «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясына таянып, Арча район Советы **карар бирде**:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының муниципаль мөлкәт Исемлегенә кертелгән, өченче затлар хокукыннан азат булган (хуҗалык алып бару хокукыннан, оператив идарә хокукыннан, шулай ук кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш), кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына биләүгә һәм (яки) файдалануга бирү өчен билгеләнгән муниципаль мөлкәтен, шул исәптән җир кишәрлекләрен (шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, яшелчәчелек, бакчачылык, шәхси торак төзелеше өчен билгеләнгән җир кишәрлекләреннән тыш) арендага бирү Тәртибен расларга (1 нче кушымта).

2. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының муниципаль мөлкәт Исемлегенә кертелгән, өченче затлар хокукыннан азат булган (хуҗалык алып бару хокукыннан, оператив идарә хокукыннан, шулай ук кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш), кече һәм урта

эшмәкәрлек субъектларына биләүгә һәм (яки) файдалануга бирү өчен билгеләнгән муниципаль мөлкәте, шул исәптән җир кишәрлекләре (шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, яшелчәчелек, бакчачылык, шәхси торак төзелеше өчен билгеләнгән җир кишәрлекләреннән тыш) Исемлеген формалаштыру, алып бару һәм мәҗбүри бастырып чыгару Тәртибен расларга.

3. Арча район Советының 2019 елның 20 августындагы 266 номерлы "Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының муниципаль мөлкәт Исемлегенә кертелгән, өченче затлар хокукыннан азат булган (хуҗалык алып бару хокукыннан, оператив идарә хокукыннан, шулай ук кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш), кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфрастуктурасын төзүче оешмаларга биләүгә һәм (яки) файдалануга бирү өчен билгеләнгән муниципаль мөлкәтен, шул исәптән җир кишәрлекләрен (шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, яшелчәчелек, бакчачылык, шәхси торак төзелеше өчен билгеләнгән җир кишәрлекләреннән тыш) арендага бирү Тәртибен һәм Исемлеккә кертелгән муниципаль мөлкәтне формалаштыру, алып бару һәм бастырып чыгару Тәртибен раслау турында" карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының Рәсми хокукый порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru адресы буенча урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Арча муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы җитәкчесе И.И.Игнатовка йөкләргә.

Арча муниципаль район башлыгы,
Арча район Советы рәисе

АРСКИЙ РАЙОННЫЙ СОВЕТ
АРЧА РАЙОН СОВЕТЫ

И.Г.Нуриев

Арча район Советының
2019 елның
13.11.2019
285 номерлы
карарына 1нче кушымта

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының муниципаль мөлкәт Исемлегенә кертелгән, өченче затлар хокукыннан азат булган (хуҗалык алып бару хокукыннан, оператив идарә хокукыннан, шулай ук кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш), кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына биләүгә һәм (яки) файдалануга бирү өчен билгеләнгән муниципаль мөлкәтен, шул исәптән җир кишәрлекләрен (шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, яшелчәчелек, бакчачылык, шәхси торак төзелеше өчен билгеләнгән җир кишәрлекләреннән тыш) арендага бирү Тәртибе**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының муниципаль мөлкәт Исемлегенә кертелгән, өченче затлар хокукыннан азат булган (хуҗалык алып бару хокукыннан, оператив идарә хокукыннан, шулай ук кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш), кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына биләүгә һәм (яки) файдалануга бирү өчен билгеләнгән муниципаль мөлкәтен, шул исәптән җир кишәрлекләрен (шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, яшелчәчелек, бакчачылык, шәхси торак төзелеше өчен билгеләнгән җир кишәрлекләреннән тыш) арендага бирү Тәртибе Россия Федерациясе Гражданлык кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль закон, "Конкуренцияне яклау турында" 2006 елның 26 июлендәге 135-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары һәм Арча муниципаль районының муниципаль хокукый актлары нигезендә эшләнде.

1.2. Исемлеккә кертелгән мөлкәтнең милекчесе булып Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы муниципаль берәмлеге тора.

1.3. Исемлекне формалаштыру, алып бару, мәҗбүри бастырып чыгару тәртибе Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Советы карары белән билгеләнә.

1.4. Тәртип Арча муниципаль районының муниципаль мөлкәт Исемлегенә кертелгән, өченче затлар хокукыннан азат булган (хуҗалык алып бару хокукыннан, оператив идарә хокукыннан, шулай ук кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының

мөлкәти хокукларыннан тыш), кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына биләүгә һәм (яки) файдалануга бирү өчен билгеләнгән муниципаль мөлкәтен, шул исәптән җир кишәрлекләрен (шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, яшелчәчелек, бакчачылык, шәхси торак төзелеше өчен билгеләнгән җир кишәрлекләреннән тыш) арендага бирү процедурасын (алга таба – Исемлек) һәм мондый мөлкәтне кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына аренда түләвенең ташламалы ставкалары буенча арендага бирү шартларын билгели.

1.5. Муниципаль мөлкәтне арендага бирүче булып Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы муниципаль милекчесенең вәкаләтләрен тормышка ашырырга вәкаләтле орган тора.

1.6. Исемлеккә кертелгән мөлкәтне арендалаучылар - «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә ярдәм күрсәтелә алмый торган кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларыннан кала, авыл хуҗалыгы кооперативлары булган яки социаль әһәмиятле эшчәнлек төрләре белән шөгыльләнүче яки муниципаль программалар (ярдәмче программалар) буенча өстенлекле эшчәнлек белән шөгыльләнүче кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары тора.

1.7. Арча муниципаль районы территориясендә эшчәнлекнең өстенлекле төрләрен күздә тоткан муниципаль программалар (ярдәмче программалар) булмаган очракта, эшчәнлекнең социаль әһәмиятле төрләре Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан билгеләнә.

## 2. Муниципаль мөлкәтне арендага бирү

2.1. Исемлеккә кертелгән мөлкәтне арендалау килешүләре төзү исемлеккә кертелгән мөлкәтне арендалау килешүләре төзү хокукына аукцион формасында ачык сату нәтиҗәләре буенча башкарыла (алга таба – сатулар).

2.2.Арендага бирүче сатуларны оештыру һәм үткәрү функцияләрен башкара.

2.3. Сатуларны үткәрү, исемлеккә кертелгән мөлкәтне арендалау шартнамәләрен төзү сатуларны үткәрү нәтиҗәләре буенча гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

2.4. Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары тарафыннан сатуларда катнашуга гаризалар бирү, гаризага кушып бирелә торган документларга таләпләр, сатуларда катнашудан баш тарту өчен нигезләр аукцион турындагы документлар белән билгеләнә.

2.5. Исемлеккә кертелгән муниципаль мөлкәтне арендалаучы субаренда шартнамәсе буенча өченче затларга үз хокукларын һәм бурычларын муниципаль мөлкәтнең гомуми арендалана торган мәйданыннан 30 процентка кадәрен бирергә хокуклы.

2.6. Арендалаучы муниципаль мөлкәтне, «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән тыюларны үтәү шарты белән, бары тик максатчан билгеләнеше буенча гына файдаланырга тиеш.

2.7. Исемлеккә кертелгән мөлкәткә карата шартнамәләр төзелә торган срок

кимендә биш ел тәшкил итәргә тиеш. Килешү срогы биләү һәм (яки) файдалану хокукын сатып алучы затның мондый шартнамә төзелгәнчегә кадәр бирелгән гаризасы нигезендә киметелергә мөмкин.

## 3. Аренда түләве һәм аны кертү тәртибе

3.1. Исемлеккә кертелгән мөлкәтне арендалау килешүләре өчен аренда түләве күләме сатуларны үткәрү нәтиҗәләре буенча билгеләнә.

3.2. Аренда килешүенең башлангыч бәясе бәяләү эшчәнлеге турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә әзерләнгән аренда түләвенең базар бәясен бәяләү турындагы хисап нигезендә билгеләнә.

3.3. Исемлеккә кертелгән мөлкәтне арендалау килешүе төзегәндә, биш ел срокка арендалаучы тарафыннан түләү түбәндәгечә кертелә:

– аренданың беренче елында-аренда килешүендә билгеләнгән аренда түләве күләменең 0 процентны;

– аренданың икенче елында-аренда килешүендә билгеләнгән аренда түләвенең 0 процентны;

– аренданың өченче елында-аренда килешүендә билгеләнгән аренда түләвенең 25 процентны;

– аренданың дүртенче елында-аренда килешүендә билгеләнгән аренда түләвенең 50 процентны;

-аренданың бишенче һәм алдагы елларында- аренда килешүендә билгеләнгән аренда түләвенең 75 процентны;

3.4. Исемлеккә кертелгән мөлкәтне арендалау килешүен яңа срокка төзегәндә, арендалаучы тарафыннан аренда түләве 100 процент күләмендә кертелә.

3.5. Килешүне вакытыннан алда өзгән очракта, арендалаучыга, сатуларны үткәрү нәтиҗәләре буенча билгеләнгән базар бәясеннән чыгып, мөлкәт белән файдалануның бөтен вакыты буенча тулысынча түләргә кирәк була.

3.6. Муниципаль милекне файдаланган өчен аренда түләве Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы бюджетына күчерелә.

Арча район Советының
2019 елның
13.11.2019
285 номерлы
карарына 2нче кушымта

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының муниципаль мөлкәт Исемлегенә кертелгән, өченче затлар хокукыннан азат булган (хуҗалык алып бару хокукыннан, оператив идарә хокукыннан, шулай ук кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш), кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына биләүгә һәм (яки) файдалануга бирү өчен билгеләнгән муниципаль мөлкәте, шул исәптән җир кишәрлекләре (шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, яшелчәчелек, бакчачылык, шәхси торак төзелеше өчен билгеләнгән җир кишәрлекләреннән тыш) Исемлеген формалаштыру, алып бару һәм мәҗбүри бастырып чыгару Тәртибе**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

**1.1.** Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының муниципаль мөлкәт Исемлегенә кертелгән, өченче затлар хокукыннан азат булган (хуҗалык алып бару хокукыннан, оператив идарә хокукыннан, шулай ук кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш), кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына, «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә мөлкәти ярдәм күрсәтү максатларында, биләүгә һәм (яки) озак вакытлы түләүле файдалануга, шул исәптән ташламалы шартларда, бирү өчен билгеләнгән муниципаль мөлкәте, шул исәптән җир кишәрлекләре (шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, яшелчәчелек, бакчачылык, шәхси торак төзелеше өчен билгеләнгән җир кишәрлекләреннән тыш) исемлеген (алга таба- Исемлек) формалаштыру, алып бару һәм бастырып чыгару ысулын билгели.

**1.2.** Исемлекне формалаштыру Арча муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы тәкъдиме буенча Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Башкарма комитеты тарафыннан гамәлгә ашырыла.

## 2. Исемлекне формалаштыру тәртибе

**2.1.** Исемлек әлеге Тәртипнең 2.2 пунктында күрсәтелгән, өченче затларның башка хокукларыннан (хуҗалык алып бару хокукыннан, оператив идарә хокукыннан тыш) азат булган, шулай ук Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы казнасы милкеннән булган муниципаль мөлкәттән төзелә.

**2.2.** Кече һәм урта эшмәкәрлек субъекты тарафыннан арендалана торган мөлкәт Исемлеккә кертелгәндә, мөлкәтне кертүгә арендалана торган мөлкәтне сатып алуга өстенлекле хокукны гамәлгә ашыру тәртибенә карата, шулай ук «Дәүләт яисә муниципаль милектә булган һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектлары арендалана торган күчемсез мөлкәтне читләштерү үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2008 елның 22 июлендәге 159-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба -

159-ФЗ номерлы Закон) нигезләмәләре турында мәгълүмат, шулай ук Исемлеккә кертелгән мөлкәтне арендалаучы кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ташламалар турында мәгълүмат җибәреп, арендалаучының тиешле ризалыгын алырга кирәк.

**2.3.** Арендага бирелгән мөлкәтне Исемлектән төшереп калдыру турындагы карар, мөлкәтне исемлектән төшереп калдыру анның бетүе яки юк ителүе, шулай ук арендалаучы тарафыннан №159-ФЗ Закон нигезендә мөлкәтне сатып алу кебек хәлләргә бәйле очраклардан тыш, арендалаучының язма ризалыгы булганда кабул ителә.

**2.4.** Исемлеккә мөлкәт турында түбәндәге критерийларга туры килә торган мәгълүматлар кертелә:

1) мөлкәт өченче затларның хокукларыннан ирекле (хуҗалык алып бару хокукыннан, оператив идарә хокукыннан, шулай ук кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының милек хокукларыннан тыш);

2) федераль законнар белән милеккә карата аны вакытлыча хуҗа булуга һәм (яки) файдалануга, шул исәптән арендага бирүгә тыю билгеләнмәгән;

3) мөлкәт дини билгеләнештәге объект булып тормый;

4) муниципаль милек "Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында" 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә кабул ителгән агымдагы елда һәм чираттагы чорга хосусыйлаштыру Планына кертелмәгән, шулай ук ачык хокукый берәмлек милкенең социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларга озак сроклы нигездә файдалануга тапшыру өчен билгеләнгән исемлегенә кертелмәгән; милеккә карата милекченең өченче затка муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында башка карары кабул ителмәгән;

5) милек авария хәлендә һәм сүтелергә тиешле дип табылмаган;

6) милек торак фондына керми һәм торак фонды объекты тоташтырылган инженер-техник тәэмин итү челтәре объекты булып тормый;

7) җир кишәрлеге шәхси ярдәмче хуҗалык, яшелчәчелек, бакчачылык, шәхси торак төзелеше алып бару өчен билгеләнмәгән;

8) кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына арендага бирелгән җир кишәрлекләреннән кала, җир кишәрлекләре Россия Федерациясе Җир кодексының 39.11 статьясындагы 8 пунктның 1-10, 13-15, 18 һәм 19 пунктларында каралган җир кишәрлекләренә карамый;

9) муниципаль унитар предприятиегә хуҗалык алып бару яки оператив идарә итү хокукында беркетелгән мөлкәткә карата, муниципаль учреждениегә хуҗалык алып бару яки оператив идарә хокукында беркетелгән мөлкәткә карата, күрсәтелгән мөлкәтне Исемлеккә кертү турында баланс тотучы тәкъдиме, шулай ук мөлкәтне Исемлеккә кертүгә тиешле мөлкәт белән алыш-бирешне килештерүгә вәкаләтле Арча муниципаль районы Башкарма комитетының язма ризалыгы булган;

10) милек куллану процессында үз табигый үзлекләрен югалткан әйберләргә (кулланыла торган әйберләр), хезмәт итү срогы биш елдан ким булган мөлкәткә яки аны Россия Федерациясе законнары нигезендә биш һәм аннан күбрәк елга арендага бирү рөхсәт ителми торган мөлкәткә керми, шулай ук бүленми торган әйбернең бер өлеше булып тормый;

11) өч елдан кимрәк вакыт эчендә кече һәм урта эшкуарлык субъекты тарафыннан арендалана торган мөлкәткә карата арендалаучы вәкаләтле органның

әлеге Тәртипнең 2.4 пунктында күрсәтелгән тәкъдименә җавап итеп Исемлеккә кертүгә каршылык җибәрмәгән;

**2.5.** Исемлеккә әлеге Тәртипнең 2.4 пунктында күрсәтелгән критерийларга туры килә торган түбәндәге мөлкәт кертелә:

1) инженер-техник тәэмин итү челтәрләренә тоташтырылган һәм транспорт инфраструктурасы объектларына керә ала торган күчемсез милек объектлары;

2) торак пунктларның чикләрендә административ, житештерү, сәүдә яки офис максатларында куллану планлаштырылган күчемсез милек объектлары;

3) муниципаль унитар предприятиегә хуҗалык алып бару яки оператив идарә итү хокукында беркетелгән, муниципаль учреждениегә хуҗалык алып бару яки оператив идарә хокукында беркетелгән, күрсәтелгән мөлкәтне Исемлеккә кертү турында баланс тотучы тәкъдиме, шулай ук мөлкәтне Исемлеккә кертүгә тиешле мөлкәт белән алыш-бирешне килештерүгә вәкаләтле Арча муниципаль районы Башкарма комитетының язма ризалыгы булган мөлкәт;

4) зурлыгы Россия Федерациясе Җир кодексының $11^9$ статьясы нигезендә билгеләнгән чик зурлыгына туры килә торган, шул исәптән авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге, шулай ук инвестиция эшчәнлеге турында Россия Федерациясе законнары нигезендә инвестиция проектларын гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән җир кишәрлекләре, шулай ук дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре.

**2.6.** Муниципаль унитар предприятиегә хуҗалык алып бару яки оператив идарә итү хокукында беркетелгән, муниципаль учреждениегә оператив идарә хокукында беркетелгән муниципаль милек Исемлеккә күрсәтелгән предприятие яки учреждение тәкъдиме буенча һәм мөлкәт белән алыш-бирешне килештерүгә вәкаләтле Арча муниципаль районы Башкарма комитетының ризалыгы белән кертелә.

**2.7.** Мөлкәтне исемлектән төшереп калдыру түбәндәге очракларда башкарыла:

1) мөлкәткә карата Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә аны муниципаль ихтыяҗлар өчен куллану турында карар кабул ителгәндә. Мөлкәтне Исемлектән төшереп калдыру турындагы карарда мөлкәтне файдалану юнәлеше һәм тиешле карарның реквизитлары күрсәтелә;

2) муниципаль милек хокукы суд карары буенча яисә законда билгеләнгән тәртиптә туктатылу;

3) бетүе яки юк ителүе нәтиҗәсендә мөлкәтнең гамәлдән чыгуы;

4) мөлкәтнең Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә физик яки мораль яктан тузуы, авария хәленә килүе нәтиҗәсендә файдалану өчен яраксыз дип танылуы;

5) мөлкәтне билгеләнгән тәртиптә федераль милеккә, Татарстан Республикасы милкенә, Татарстан Республикасының Арча муниципаль районы составына керүче шәһәр һәм авыл җирлекләре милкенә тапшыру;

**2.8.** Мөлкәт исемлеге Арча муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән раслана.

## 3. Исемлекне алып бару тәртибе

**3.1.** Исемлек Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы тарафыннан кәгазь һәм электрон формада алып барыла.

**3.2.** Исемлек түбәндәге белешмәләрне үз эченә алган реестрдан гыйбарәт:

- тәртип буенча номер;
- мөлкәтнең реестр номеры;
- муниципаль күчемсез мөлкәтнең урнашу урыны;
- күчемсез мөлкәтнең объекты төре;
- мөлкәтнең идентификация белешмәләре (кадастр номеры һ. б.);
- мөлкәт характеристикасы (мәйданы, катлары, озынлыгы һ. б.);
- муниципаль мөлкәтнең атамасы;
- мөлкәтнең хокуклы хуҗасы;
- мөлкәткә карата чикләүләр (авырлык) турында мәгълүмат.

## 4. Исемлекне бастырып чыгару тәртибе

**4.1.** Исемлек һәм аңа кертелә торган үзгәрешләр "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар Рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча, "Интернет" челтәрендә Арча муниципаль районы рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru адресы буенча мәҗбүри бастырып чыгарылырга тиеш.